Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Лубян авыл җирлеге Советы

21.12 2020 №29

К А Р А Р

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Карары нигезендә Лубян авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Лубян авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.1. Муниципаль берәмлек Башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 15 759 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «11163» санын «11498» саны белән алмаштырырга

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Лубян авыл җирлеге
башлыгы: Г.Ф.Тежикова